| СОВЕТ РУССКО-АЗЕЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РУС ӘҖИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 24 июле Рус Әҗиле авылы № 125

Рус Әҗиле авыл җирлеге Советының 2017 елның 29 ноябрендагы № 89 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Рус Әҗиле авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (Советның 2018 елның 26 апрелендәге 100 номерлы, 2019 елның 15 февралендәге 139 номерлы, 2020 елның 4 августындагы 189 номерлы, 2021 елның 13 июлендәге 39 номерлы, 2022 елның 19 декабрендәге 91 номерлы, 2023 елның 16 гыйнварындагы 100 номерлы, 2023 елның 09 февралендәге 107 номерлы, 2023 елның 14 апрелендәге 112 номерлы) карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, муниципаль хезмәт турындагы Татарстан Республикасы кодексына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Рус Әҗиле авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Рус Әҗиле авыл җирлеге Советының 2017 елның 29 ноябрендагы № 89 карары белән расланган (Советның 2018 елның 26 апрелендәге 100 номерлы, 2019 елның 15 февралендәге 139 номерлы, 2020 елның 4 августындагы 189 номерлы, 2021 елның 13 июлендәге 39 номерлы, 2022 елның 19 декабрендәге 91 номерлы, 2023 елның 16 гыйнварындагы 100 номерлы, 2023 елның 09 февралендәге 107

номерлы, 2023 елның 14 апрелендәге 112 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 29.3 пунктның 1 пунктчасы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) «Коррупциягә каршы тору турында»гы 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты хакимиятенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте үткәргән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталының Интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Рус Әҗиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Рус Әҗиле авылы, Центральная урамы, 1йорт (җирлек администрациясе бинасы), Карәшәм авылы, Новая урамы, 27 йорт (мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

Рус Әҗиле авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Т.Ф.Семахина